ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.12.2025 г. Казань № 660-14/э-2025

Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте электр энергиясен гарантияле тәэмин итүчегә 2026 елга сату өстәмәләре билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя кую турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 31 октябрендәге 3081-р номерлы күрсәтмәсе, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аналогларны чагыштыру ысулын кулланып гарантияле тәэминатчыларның сату өстәмәләрен исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2017 елның 21 ноябрендәге 1554/17 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 18.12.2025 ел, №34-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең электр энергиясен гарантияле рәвештә җиткерүчесенә 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр, әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән сату өстәмәләрен билгеләргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2025 № 660-14/э-2025 карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең электр энергиясен гарантияле рәвештә җиткерүчесенә 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән сату өстәмәләре (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелә)

сум/кВт сәг

| Т/с | Оешманың атамасы | Сату өстәмәсе | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | халык һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категорияләре | | югалтуны компенсацияләү өчен электр энергиясен сатып алучы челтәр оешмалары | | үзләренең энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге 670 кВт ким булмаган башка кулланучылар | | үзләренең энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге 670 кВт башлап 10 МВт кадәр булган башка кулланучылар | | үзләренең энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге кимендә 10 МВт булган башка кулланучылар | |
| | | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 01.01.2026 башлап 30.09.2026 кадәр | 01.10.2026 башлап 31.12.2026 кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 1. | «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте | 0,7971 | 0,7972 | 0,2542 | 0,2541 | 0,3216 | 0,5214 | 0,1295 | 0,1738 | 0,1072 | 0,1738 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге